МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

ул.Казакова, д.9б, п.г.т. Алексеевское, 422900

МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ»

Казаков ур., 9б йорт, Алексеевск ш.т.б., 422900

Телефоны: (84341) 2-47-49, (84341) 2-48-44, E-mail: Roo.Alx@tatar.ru, https://edu.tatar.ru/alekseevo/aleks

____________ № ______

**Бөтенроссия күләмендә үткәрелә торган ана теле һәм әдәбияты укытучыларының “Туган тел” мастер-класс бәйгесен оештыру комитетына**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының “Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 2 нче Алексеевск гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Чибинова Лилия Рәис кызы хезмәтенә бәяләмә**

Лилия Рәис кызы Чибинова “Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 2 нче Алексеевск гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесендә 2011 елдан бирле татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Әлеге мәктәптә эшләү дәверендә ул үзен сәләтле, тырыш, үз эшен яратучы укытучы, тәртипле хезмәткәр итеп танытты. Аның дәресләре укучыларда зур кызыксыну уята, чөнки Лилия Рәисовна дәресләргә бай материал туплап, зур хәзерлек белән керә. Укытучы үз-үзен тотышы, эмоциональ матур сөйләме белән укучыларда туган җиргә, туган телгә мәхәббәт, ата-анага, өлкәннәргә карата шәфкатьлелек хисләре тәрбияли. Ул укучыларның мөстәкыйль рәвештә фикерләү сәләтен үстерүгә, грамоталы язуларына һәм сәнгатьле укуларына нык игътибар итә. Балаларга шәхес буларак каравы нәтиҗәсендә укытучының укучылар арасында авторитеты зур. Балалар аны яраталар, хөрмәт итәләр. Ул аларның өлкән дусты да, киңәшчесе дә, сердәшчесе дә.

Лилия Рәисовна эш тәҗрибәсен коллегалары белән уртаклаша. Район татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен ачык дәресләр, сыйныфтан тыш чаралар күрсәтә, семинарларда чыгышлар ясый: 4нче сыйныфта “Мин чисталык яратам” , 5нче сыйныфта “Телефоннан сөйләшү этикеты” дигән темаларга ачык дәресләр күрсәтелде. Район семинарларында ясаган чыгышлары да зур әһәмияткә ия. Мәсәлән: “Укучыларны БДТ га әзерләү”, “Сәләтле укучылар белән эш тәҗрибәсеннән”.

Лилия Рәисовнаның укучылары шигырь сөйләүчеләр, иҗади бәйгеләрдә, фәнни-гамәли конференцияләрдә актив катнашып, призлы урыннар яулаучылар: “Без яшь,без сәләтле" республикакүләм фәнни-гамәли конференцияләрдә 2 урын, 2012 ел; “Зирәк тиен” конкурсында, 1урын, 2013 ел; “Илһам” – яшь язучылар конкурсында 2 тапкыр лауреат, 2016 ел һәм 2017 ел; “Үткәнгә бару”бәйгесендә 1нче, 2нче урыннар, 2013 һәм 2014еллар; районара үткәрелгән “Бу минем дөньям” бәйгесендә 1 нче, 2нче урыннар, 2013ел; VI халыкара ”Тукай укулары”бәйгесендә район күләмендә 1 урын, республикада катнашучы; “Рождественские чтения”республикакүләм фәннигамәли конференциясендә 1урын, 2017ел һ.б.

Шулай ук аның укучылар татар теленнән үткәрелгән республика олимпиадасының муниципаль этабында уңыш яулаучылар: 2015-2016 уку елы,1 җиңүче, 2 призер; 2017-2018 уку елы, 1җиңүче, 1 призер.

Лилия Рәиновна үз эшендә коммуникатив технологияләрне уңышлы файдалана. Алдынгы эш тәҗрибәсен гомумиләштереп, аны матбугат битләре аша яктыртуга зур игътибар бирә. Районда чыга торган “Таң” газетасында “Чара күңелле үтте”, “Г.Тукай юбилее”, ”Ватаным Татарстан” газетасында “Көчле рухлылар” мәкаләләре бастырылды. Шулай ук www.pedmasterstvo.ru , http://infourok.ru сайтларында дәрес эшкәртмәләре урын алды. Яр Чаллы шәһәрендәуздырылган семинарда “Актуальные аспекты реализации ФГОС” – чыгыш ясаучы һ.б.

Тырыш хезмәте, яшь буынны укыту һәм тәрбияләү өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен район мәгариф бүлеге грамотасы белән бүләкләнде.

Лилия Рәисовна яңалыкка омтылучан, һөнәри осталыгын күтәрү өстендә даими эшләүче югары культуралы педагог. Хезмәт вазифаларын намус белән башкара һәм иҗади эшләргә ярата.Шуңа күрә тырыш хезмәте, тынгысыз җаны белән хезмәттәшләре,укучылары һәм ата-аналарның ихтирамын казанды.

**МКУ “ Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**мәгариф бүлеге”**
**җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Л.Н.Кирюхина**